**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменения в Земельный кодекс Республики Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
25 сентября 2015 года

**Статья 1**

Внести в Земельный кодекс Республики Татарстан (в редакции Закона Республики Татарстан от 18 января 2005 года № 4-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 1998, № 8 (II часть); 1999, № 8 (I часть); 2005, № 1 (I часть), № 12 (I часть); 2006, № 7 (I часть); 2007, № 1 (I часть), № 4; 2008, № 5 (I часть); 2009, № 7 – 8 (III часть); 2010, № 11; 2011, № 11 (I часть); 2012, № 3, № 5 (I часть); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II часть), № 7, № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть) изменение, дополнив его статьей $33^3$ следующего содержания:

«Статья $33^3$. **Предоставление земельных участков, находящихся в государственной или муниципальной собственности, в аренду для размещения объектов социально-культурного и коммунально-бытового назначения, реализации масштабных инвестиционных проектов**

1. Договор аренды земельного участка, находящегося в государственной собственности, в том числе земельного участка, государственная собственность на который не разграничена, или земельного участка, находящегося в муниципальной собственности, заключается без проведения торгов в случае предоставления земельного участка юридическим лицам в соответствии с распоряжением Президента Республики Татарстан для размещения объектов социально-культурного и коммунально-бытового назначения, реализации масштабных инвестиционных проектов при условии соответствия указанных объектов, инвестиционных проектов критериям, определенным настоящей статьей.

2. Предоставление земельного участка для размещения объектов социально-культурного и коммунально-бытового назначения допускается в случае, если такие объекты соответствуют приоритетам и целям, определенным в документах стратегического планирования, программах социально-экономического развития

Республики Татарстан, муниципальных образований, и являются объектами культуры, искусства, кинематографии, спорта, благоустройства, здравоохранения, образования и воспитательной работы, социальной защиты и социального обслуживания, коммунального хозяйства, бытового обслуживания населения, а также гидротехническими сооружениями, многоуровневыми и (или) подземными стоянками (парковками), многоэтажными гаражами.

3. Предоставление земельного участка в целях реализации масштабного инвестиционного проекта допускается в случае, если масштабный инвестиционный проект соответствует одному из следующих критериев:

1) создание или увеличение количества рабочих мест;

2) требование к предполагаемому объему инвестиций;

3) увеличение ежегодных поступлений от налогов, взимаемых на территории Республики Татарстан;

4) строительство индивидуальных жилых домов и (или) многоквартирных домов для предоставления мер по защите прав граждан – участников долевого строительства многоквартирных домов, пострадавших от действий (бездействия) недобросовестных застройщиков.

4. Качественные и (или) количественные показатели критериев, указанных в пункте 3 настоящей статьи, устанавливаются Президентом Республики Татарстан.

5. Юридическое лицо, заинтересованное в предоставлении ему земельного участка по предусмотренным настоящей статьей основаниям, обращается в Кабинет Министров Республики Татарстан или уполномоченный им орган и представляет документы о соответствии объекта социально-культурного и коммунально-бытового назначения, масштабного инвестиционного проекта указанным в настоящей статье критериям. Предложение о предоставлении юридическому лицу земельного участка вносится Президенту Республики Татарстан Кабинетом Министров Республики Татарстан с мотивированным заключением о соответствии объекта социально-культурного и коммунально-бытового назначения, масштабного инвестиционного проекта указанным в настоящей статье критериям. Договор аренды земельного участка с юридическим лицом заключается на основании распоряжения Президента Республики Татарстан исполнительным органом государственной власти Республики Татарстан или органом местного самоуправления, уполномоченными на распоряжение земельными участками, в порядке, установленном земельным законодательством.

6. Порядок представления юридическим лицом документов, предусмотренных пунктом 5 настоящей статьи, их перечень и порядок рассмотрения устанавливаются Кабинетом Министров Республики Татарстан.».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан принять нормативные правовые акты, обеспечивающие реализацию настоящего Закона, в течение 30 дней со дня вступления в силу настоящего Закона.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
7 октября 2015 года
№ 67-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), түбәндәге эчтәлекле $33^3$ статья өстәп, үзгәреш кертергә:

«$33^3$ статья. **Дәүләт яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектлар урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен арендага бирү**

1. Дәүләт милкендәге җир кишәрлеген, шул исәптән дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлеген, яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе, Татарстан Республикасы Президенты күрсәтмәсе нигезендә җир кишәрлеге юридик затларга социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектлар урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен бирелгән очракта, күрсәтелгән объектларның, инвестиция проектларының әлеге статьяда билгеләнгән критерийларга туры килү шарты белән, торглар үткәрмичә төзелә.

2. Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектлар стратегик планлаштыру документларында, Татарстан Республикасының, муниципаль

берәмлекләрнең социаль-икътисадый үсеш программаларында билгеләнгән өстенлекләргә һәм максатларга туры килсә һәм мәдәният, сәнгать, кинематография, спорт, төзекләндерү, сәламәтлек саклау, мәгариф һәм тәрбия эше, социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү, коммуналь хуҗалык, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, күпкатлы һәм (яисә) җир асты машина кую урыннары (парковкалар), күпкатлы гаражлар булып торса, җир кишәрлеген мондый объектларны урнаштыру өчен бирү рөхсәт ителә.

3. Җир кишәрлеген масштаблы инвестиция проектын гамәлгә ашыру максатларында бирү масштаблы инвестиция проекты түбәндәге критерийларның берсенә туры килгән очракта рөхсәт ителә:

1) эш урыннары булдыру яисә аларның санын арттыру;

2) инвестицияләрнең күздә тотыла торган күләменә таләп;

3) Татарстан Республикасы территориясендә түләнә торган салымнардан еллык керемнәрнең артуы;

4) намуссыз застройщиклар гамәлләреннән (гамәл кылмауларыннан) зыян күргән гражданнарның – күпфатирлы йортлар төзүдә өлешле катнашучыларның хокукларын яклау чараларын күрү өчен шәхси торак йортлар һәм (яисә) күпфатирлы йортлар төзү.

4. Әлеге статьяның 3 пунктында күрсәтелгән критерийларның сыйфат һәм (яисә) сан күрсәткечләре Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.

5. Әлеге статьяда каралган нигезләр буенча җир кишәрлеге алуда кызыксынган юридик зат Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына яисә ул вәкаләт биргән органга мөрәҗәгать итә, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектның, масштаблы инвестиция проектының әлеге статьяда күрсәтелгән критерийларга туры килүе турында документлар тапшыра. Юридик затка җир кишәрлеге бирү турындагы тәкъдим социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектның, масштаблы инвестиция проектының әлеге статьяда күрсәтелгән критерийларга туры килүе турында дәлилле бәяләмә белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасы Президентына кертелә. Юридик зат белән җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе Татарстан Республикасы Президенты күрсәтмәсе нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы яисә җир кишәрлекләре белән эш йөртүгә вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан җир турындагы законнар нигезендә билгеләнгән тәртиптә төзелә.

6. Юридик зат тарафыннан әлеге статьяның 5 пунктында каралган документларны бирү тәртибе, аларның исемлеге, карау тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып 30 көн эчендә шушы Законның гамәлгә ашырылуын тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2015 елның 7 октябре
№ 67-ТРЗ